**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре № 2

**2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Шөгер авыл җирлегенең Шөгер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге Шөгер авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1.2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Шөгер авыл җирлеге Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән (дүрт һәм аннан да күбрәк бала), Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, МХОдә катнашучылардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

2.1.торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Шөгер авылына Октябрь тыкрыгы, Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил, Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, Почта, К. Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, П. Коммуна, Зөбәй, Габбасов тыкрыгы буенча юлларны кардан чистарту
- Вак таш белән чокыр ремонтлау, К. Маркс урамы, Җәлил урамы
- Сәйдәшев урамында асфальт белән чокыр ремонтлау

2.2.җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлыштырып,җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү,:
- Шөгер авылында Завод, Ибраһимов, Киров, Ленин, Герцен, Тукай, Җәлил, Сәйдәшев, Гагарин, Гафиятуллин, Такташ, почта, Маркс, Горький, Больничная, Павленко, Садовая, Пушкин, Халиков, Коммуна, Зөбәй, Габбасов тыкрыгы, Такташ урамнары,Октябрь тыкрынгында урамнарны яктыртуны ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү
- Берьеллык чәчәкләр алу
- Паркка эскәмияләр сатып алу
-Урналар сатып алу
-Габбасов тыкрыгында авария хәлендәге агачларны кисү

2.3.торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру
- Шөгер авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм төзү.
2.4. халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, ---спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
стадионда һәм авылныж «Юность» паркында үлән чабу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров ур., 17, балалар бакчасы, Киров ур., 23, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин ур., 32, Шөгер авыл мәдәният йорты, Ленин ур., 35, Шөгер 3 участок хастаханәсе, Горький ур., 4 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы

Р.Н.Гафиятуллин